**IҮ ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГЕЛДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ XXXXII УТЫРЫШЫ**

**КАРАР № 73**

Тойгелде авылы 31.07.2024 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Тойгелде авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмә турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советының 16.12.2020 елның 9 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96-6 һәм 220-1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының « Тойгелде авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмә турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советының 16.12.2020 елның 9 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр 3 пунктның 28, 31статьяларын гамәлдә булуын туктатып торырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма калдырам.

Тойгелде авыл җирлеге Башлыгы Минһаҗев Д.М.